**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«МУСАБАЙ-ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

«17» ноябрь 2023 ел № 4/1

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге уставының 20, 95-97 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Җирлек Советының 2019 елның 24 сентябрендәге 48/1 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары проектын 1 кушымта нигезендә беренче укылышта кабул итәргә һәм аны халык тыңлауларына чыгарырга.

2. Расларга:

- «Җирлек Советының 2019 елның 24 сентябрендәге 48/1 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турында» Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен 2 кушымта нигезендә;
- «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары проекты буенча халык тыңлауларын үткәрү тәртибен 3 кушымта нигезендә.

3. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм естәмәләр кертү турында» карар проекты буенча халык тыңлауларын 2023 елның 08 декабрендә 14.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча үткәрергә дип билгеләргә: ТР, Тукай районы, Мусабай-Завод авылы, Ленин ур., 33А йорт.

4. Түбәндәге составта халык тыңлауларын үткәрү буенча комиссия төзергә:

1) Хесәинова З.З. – комиссия рәисе;
2) Вильданова Л.Р. – комиссия әгъзасы;
3) Калимуллина С.Р. – комиссия әгъзасы.

5. Халык тыңлауларын үткәрү буенча комиссиягә халык тыңлауларын үткәрүне, әлеге карар проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6. Законлылык, хокук тәртибе, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә халык тыңлауларында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм җирлек Советы каравына кертергә.

7. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе З.З. Хесәинова

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Заводавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 17 ноябрендәге 4/1 номерлы карарына 1 кушымта

**«Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советы карары проекты**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2021 елның 11 июнендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге уставының 20, 95-97 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2019 елның 24 сентябрендәге 48/1 номерлы Совет карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Заводавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына түбәндәге үзгәрешләрне һәм естәмәләрне кертергә:

**1.1 <u>11 маддәнең 7 пункты 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«Әгәр җирле референдум җирлек Советы тарафыннан билгеләнгән срокларда билгеләнмәгән очракта, референдум гражданнар, сайлау берләшмәләре, җирлек башлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Сайлау комиссиясе яки Тукай муниципаль районы прокуроры мерәҗәгате нигезендә суд тарафыннан билгеләнә. Суд билгеләгән җирле референдумны җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба – сайлау комиссиясе) оештыра, ә аны үткәрүне тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы яки суд тарафыннан җирле референдум үткәрүне тәэмин итү йөкләнгән башка орган тарафыннан башкарыла.»;

**1.2 <u>12 маддәнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«4. Муниципаль сайлауларны әзерләү һәм үткәрү җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссияләренә (алга таба – сайлау комиссиясе) аларның компетенциясе чикләрендә йөкләнә.»;

**1.3. <u>13 маддәнең 5, 8, 12 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«5. Инициатив теркем җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясенә (алга таба – сайлау комиссиясе) инициатив теркемне теркәү турында үтенечнамә белән мөрәҗәгать итә. Инициатив теркемнең үтенечнамәсендә җирлек Советы депутатының, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасының, җирлек башлыгының конкрет хокукка каршы карарына яки гамәлләренә (гамәл кылмавына) күрсәтмә булырга тиеш, ул аны чакыртып алу өчен нигез булып тора, гражданның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган кене һәм урыны, паспортының яки аны алыштыручы документның сериясе, номеры һәм датасы, аны биргән органның исеме яки коды, шулай ук инициатив теркемнең һәр әгъзасының һәм аның исеменнән җирлек территориясендә эш итәргә вәкаләтле затларның яшәү урыны адресы күрсәтелергә тиеш. Инициатив теркем үтенечнамәсе күрсәтелгән теркемнең барлык әгъзалары тарафыннан имзаланырга тиеш. Үтенечнамәгә суд карары теркәлергә тиеш, ул күрсәтелгән хокука каршы карарны яки депутатның гамәлләрен (гамәл кылмавын) раслый.
8. Сайлау комиссиясе инициатив теркемнең үтенечнамәсен караганда, җирлек Советы депутатын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, җирлек башлыгын чакыртып алу буенча җирлек Советы тарафыннан тавыш бирүне билгеләгәндә, тиешле депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирлек башлыгы аны чакыртып алу ечен нигез буларак тәкъдим ителә торган шартлар турында аңлатмалар бирергә, кирәкле документларны тапшырырга хокуклы. Әлеге депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирлек Башлыгына алдан, сайлау комиссиясе, җирлек Советы утырышлары уздыру кененә кадәр еч көннән дә соңга калмыйча, аларны үткәрү вакыты һәм урыны турында язмача хәбәр ителергә тиеш.
12. Сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүгә рәсми йомгак ясаганнан соң, биш көн эчендә инициатив теркемгә, җирлек Советына һәм җирлек Советының тиешле депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы орган әгъзасына, җирлек Башлыгына аны чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында язмача хәбәр итә.

**1.4 <u>31 маддәнең 10, 11 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«10. Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары нигезендә җирлек Советы депутаты, җирлек Башлыгы, җирле үзидарәнең башка сайланулы вазыйфаи заты тарафыннан тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мелкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрнең дереслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) (Татарстан Республикасы Премьер-министры) карары нигезендә Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.
11. Әлеге маддәнең 10 елеше нигезендә үткәрелгән тикшерү нәтиҗәсендә «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләгән затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Затларның аерым категорияләренә Россия Федерациясе территориясе чикләреннән тышта урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм тотуны, саф акча средстволарын һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 79-ФЗ Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, вазыйфаларны башкармау фактлары ачыклаганда, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) (Татарстан Республикасы Премьер-министры) җирлек Советы депутаты, сайланулы җирле үзидарә органы әгъзасы, җирлек Башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яки күрсәтелгән затларга карата башка җаваплылык чарасын куллану турында гариза белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яки судка мерәҗәгать итә.»;

1.5 <u>31 маддәнең 14 пункты үз көчен югалткан;</u>

1.6 <u>33 маддәнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>

«1. Яңа чакырылыш җирлек Советы беренче утырышка депутатларның билгеләнгән саныннан ечтән ике елеше сайланган көннән соң ун көннән дә соңга калмыйча җыела. Сайлаулардан соң беренче утырыш – җирлек Башлыгы, ә ул булмаган очракта, җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба – сайлау комиссиясе) тарафыннан чакырыла.»;

1.7 <u>34 маддәнең 1 өлеше 13 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:</u>

«13) җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба – сайлау комиссиясе) әгъзаларын билгеләү»;

1.8 <u>39 маддәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>

«3. Җирлек Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба – сайлау комиссиясе) җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар үз көченә кергәннән соң 14 көннән дә соңга калмыйча, ул җирлек Советы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатканнан соң алты айдан да соңга калмыйча үткәрелә.»;

1.9 <u>41 маддәнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>

«7. Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) (Татарстан Республикасы Премьер-министры) җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез барлыкка килү көне булып җирлек Советына әлеге гаризаның керү көне тора.

1.10 <u>43 маддәнең 1 пункты 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>

«Җирлек Башлыгын сайлау җирлек Советы депутатлары тәкъдим иткән кандидатлар арасыннан, шул исәптән җирлек, иҗтимагый берләшмәләр, Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) тәкъдимнәре нигезендә башкарыла.»;

1.11 <u>47 маддәнең 3 пункты 2 абзацын, 4 пунктынтүбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>

«Аңа карата Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) (Татарстан Республикасы Премьер-министры) тарафыннан аны вазыйфадан азат итү турында хокукый акт чыгарылган җирлек Башлыгы әлеге хокукый актка рәсми басылып чыккан көннән соң 10 көн эчендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы. Суд шикаятьне карарга һәм, аны тапшырган көннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча, карар кабул итәргә тиеш.
4. Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) (Татарстан Республикасы Премьер-министрының) аны вазыйфадан азат итү турында хокукый акты яки җирлек Советының җирлек Башлыгын отставкага җибәрү турында карары нигезендә вәкаләтләре туктатылган җирлек Башлыгы әлеге хокукый актка яки карарга шикаять биргән очракта, җирлек Советы суд карары законлы көченә кергәнче, җирлек Башлыгын сайлау турында карар кабул итәргә хокуклы түгел.»;

**1.12 <u>54 маддәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«1. Җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба – сайлау комиссиясе) муниципаль сайлаулар, җирле референдум, җирле үзидарә Советы депутатын, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасын, җирлек Башлыгын чакыртып алу буенча тавыш бирүне, җирлек чикләрен үзгәртү, җирлекне үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне оештыра.
2. Сайлау комиссиясе җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасына керми торган муниципаль орган булып тора.
3. Сайлау комиссиясе «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законда, Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән тәртиптә җирлек Советы тарафыннан төзелә.
4. Сайлау комиссиясенең вәкаләтләр срогы биш ел тәшкил итә.
5. Сайлау комиссиясе хәлиткеч тавыш бирү хокукы белән 6 кешедән төзелә.
6. Сайлау комиссиясе эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү җирлек бюджетында Россия Федерациясе бюджетларының чыгымнары классификациясе нигезендә аерым юл белән карала.
7. Сайлау комиссиясе вәкаләтләре, аның эшчәнлеге тәртибе һәм гарантияләре федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге устав белән җайга салына. Җирлек Советы мөрәҗәгате нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча сайлау комиссиясе вәкаләтләре территориаль сайлау комиссиясенә йөкләнергә мөмкин.»;

**1.13 <u>56 маддәнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы – әлеге устав, җирле үзидарә органы, җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба - сайлау комиссиясе) яки муниципаль вазыйфаны биләүче зат вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча билгеләнгән вазыйфалар даирәсе нигезендә барлыкка килә торган җирле үзидарә органындагы, сайлау комиссиясе аппаратындагы вазыйфа.

**1.14 <u>57 маддәнең 1, 3 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар булып депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, муниципаль брәмлекнең даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булып торучы, җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясенең (алга таба - сайлау комиссиясе) хәлиткеч тавыш хокукына ия, комиссиядә даими (штат) нигездә эшләүче әгъзасы тора.
3. Җирле үзидарә органнары, сайлау комиссиясе эшчәнлеген техник тәэмин итү буенча вазыйфаларны башкаручы затлар муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләми һәм муниципаль хезмәткәрләр булмый.»;

**1.15 <u>58 маддәнең 1 өлеше 5 пунктын, 3 өлеше 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«5) билгеләнгән тәртиптә вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүмат һәм материаллар алу, шулай ук җирле үзидарә органы, җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау

комиссиясе (алга таба – сайлау комиссиясе) эшчәнлеген камилләштерү турында тәкъдимнәр кертү;
4) җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында билгеләнгән эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен, вазыйфаи инструкцияне, хезмәт мәгълүматы белән эшләү тәртибен үтәргә;»;

**1.16 <u>59 маддәнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә</u>:**

«2. Җирле үзидарә органы, җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба – сайлау комиссиясе) юкка чыгарылу яки җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе аппараты хезмәткәрләре штаты кыскару сәбәпле муниципаль хезмәткәрләр белән хезмәт килешүе езелгәндә, муниципаль хезмәткәргә, оешма бетерелүгә яисә оешма хезмәткәрләре штаты кыскартылуга бәйле рәвештә эштән азат ителгән очракта, хезмәт законнары белән билгеләнгән гарантияләр бирелә.»;

**1.17 <u>65 маддәнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«3. Җирле үзидарә органнарына сайлауларны, җирле референдумны әзерләүне һәм үткәрүне оештыручы сайлау комиссиясе (алга таба – сайлау комиссиясе) әгъзаларына әлеге органнар эшендә катнашкан вакытка законнар, җирлек Советы карарлары нигезендә акчалата компенсация түләнә.

**1.18 <u>72 маддәнең 1 пункты 1, 2 өлешләре, 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«1) затның ул бер ягы булган мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча чаралар күрмәве, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш;
2) затның үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирмәве, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, яки белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган мәгълүмат бирүе;
2. Муниципаль вазыйфаны биләүче затка аның кул астындагы затның мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынуы барлыкка килүе турында билгеле булганда, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм (яки) җайга салу буенча чаралар күрмәгән очракта, шулай ук ышаныч югалту сәбәпле, ул эштән (вазыйфадан) азат ителергә тиеш, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш.»;

**1.19 <u>88 маддәнең 7 өлеше 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:</u>**

«- Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең) Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасы;»

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Заводавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 17 ноябрендәге 4/1 номерлы карарына 2 кушымта

**«Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның буенча фикер алышуда катнашу тәртибе**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча тәкъдимнәр Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод выл җирлеге Советына язма рәвештә төзәтмәләр таблицасы формасында түбәндәге үрнәк нигезендә кертелә:

| № | Пункт, пунктча | Карар проектының тексты | Төзәтелгән текст | Төзәтүне исәпкә алып, карар проекты тексты | Төзәтмәләр авторы (фамилиясе,исеме, атасының исеме, адресы, телефоны, эш (уку) урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |

түбәндәге адрес буенча җибәрелә: ТР, Тукай районы, Мусабай-Завод авылы, Ленина ур., 32 йорт;

почта аша:, ТР, Тукай районы, Мусабай-Завод авылы, Ленин ур., 32 йорт

яисә факс буенча 8(8552)79-63-36.

Тәкъдимнәр карар проекты җирлекнең мәгълүмат стендаларынада урнаштырылган кеннән 2023 елның 01 декабренә кадәр эш кеннәрендә 8:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукы белән катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: ТР, Тукай районы, Мусабай-Завод авылы, Ленин ур., 32 йорт;

почта аша: ТР, Тукай районы, Мусабай-Завод авылы, Ленин ур., 32 йорт

яисә факс буенча 8(8552) 79-63-36.

Гаризалар, халык тыңлауларын үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча, эш кеннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Заводавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2023 елның 17 ноябрендәге 4/1 номерлы карарына 3 кушымта

**«Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карары буенча халык тыңлауларын үткәрү тәртибе**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Заводавыл җирлеге Советы карары буенча халык тыңлаулары (алга таба – халык тыңлаулары) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге уставының 20 статьясы нигезендә үткәрелә.

2. Халык тыңлауларында үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән катнашучылар булып, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Советына халык тыңлауларын үткәрү датасына кадәр җиде көннән дә соңга калмыйча язма гаризалар тапшырган район халкы тора.

3. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукыннан башка барлык кызыксынган җирлек халкы катнаша ала.

4. Катнашучылар халык тыңлаулары башланырга 30 минут кала теркәлә башлый.

5. Халык тыңлауларында җирлек башлыгы рәислек итә.

6. Халык тыңлаулары рәислек итүченең катнашучыларга фикер алышына торган мәсьәләнең асылы, тыңлаулар үткәрү тәртибе турында хәбәр итүче кереш сүзе белән ачыла.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, искәрмәләрне исәпкә алу өчен, рәислек итүче тәкъдиме буенча секретариат җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында халык тыңлаулары секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән эшче төркем әгъзасы чыгыш ясый.

9. Чыгыш ясау хокукы белән халык тыңлауларында катнашучылар, гариза бирү вакытына карап, чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.

10. Халык тыңлауларында катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артмаска тиеш.

11. Халык тыңлауларында катнашучылар, чыгыш тәмамланганнан соң, рәислек итүче рехсәте белән чыгыш ясаучыларга сораулар бирергә хокуклы.

12. Халык тыңлауларында катнашучылар халык тыңлаулары барышына кысылырга, аны езәргә һәм үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

13. Халык тыңлауларын үткәргәндә тәртип саклау халык тыңлауларында катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Катнашучылар тарафыннан халык тыңлауларын үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

15. Чыгышлар тәмамланганнан соң, рәислек итүче халык тыңлаулары барышында әйтелгән тәкъдимнәрне, искәрмәләрне ачыклау өчен, халык тыңлаулары секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мемкин.

16. Тыңлауларда катнашучыларның барлык искәрмәләре һәм тәкъдимнәре халык тыңлаулары беркетмәсенә кертелә. Беркетмә билгеләнгән тәртиптә авыл җирлеге Советы материалларында саклана.

17. Халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә эшче теркем тарафыннан әзерләнә.

18. Халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә халыкка игълан ителергә тиеш.

19. Халык тыңлауларын үткәрүне оештыру һәм матди-техник тәэмин итү авыл җирлеге Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.